Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«11» ноябрь 2021 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Гайтән торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Гайтән авыл территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Авыл эчендәге юлларны, шул исәптән, сезонлы карап тоту һәм таш түшәү, төзелеш контроле өчен түләү белән карап тоту һәм ремонтлау.
2) Гайтән авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу.
3) Гайтән торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.
4) Гайтән торак пунктында паркны төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру, территорияне коймалау һәм эскәмияләр алу).
5) Гайтән авылы зираты территориясен төзекләндерү.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева